

23 апрельдә беренчеләрдән булып «Движение Первых» хәрәкәтенен беренчел бvлеге активистлары, Темников медицина колледжы студентлары 1934 елда туган һәм «Сугыш балалары» категориясенә караган Садия Зәки кызы Позднякова булдылар.
Садия Зәки кызы, олы яшьтә булуына карамастан, кунакларына Боек Ватан сугышы еллары бvген булган тосле, ачлык, йорәкне оздергеч салкын һәм курку белән очрашырга туры килгән авыр еллар турында жанлы һәм эмоциональ рәвештә сойләде.

Студентлар игътибар белән тынладылар, һәр сvзне уртаклаштылар. Алар сугыш чоры балалары кичергән авыртуны һәм мәхрvмлекләрне тоя алдылар. Бигрәк тә әтисенен фронттан кайтуы кvнелне нечкәртерлек иде. Садия Зәки кызы бу конне вактояккә хәтле хәтерли: ничек итеп ул әтисен каршыларга йогергән, ничек итеп аны кочаклап алган һәм жибәрә алмаган...
Бу очрашу студентлар очен тарих һәм ватанпәрвәрлек дәресе булды: алар тере тарихка кагыла алдылар.